СОВЕТ КУЮК-ЕРЫКСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Гагарина, д.29, с.Куюк-Ерыкса,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422151

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӨЕК-ЕРЫКСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Гагарин ур., 29 нче йорт, Көек-Ерыкса авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422151

тел.(факс): (85563) 3-66-33; e-mail: Kuer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

---

Решение | Карар

« 20 » сентябрь 2017 ел | № 2-23

Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында" 23.03.2004 № 23-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Көек-Ерыкса авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдумны үткәрергә:
««Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2018 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. **Торак пункт чикләрендә су белән тәэмин итү, су чыгару оештыру:**
   Көек-Ерыкса т.п. су башнясын алыштыру;
   Көек-Ерыкса т.п. (2 шт), Яңа Комазан т.п., Зур Шыя т.п., Малмыжка т.п., Гришкино т.п. су алу башняларын койма белән әйләндерү;
   Көек-Ерыкса т.п. (2 шт), Яңа Комазан т.п., Зур Шыя т.п., Малмыжка т.п., Гришкино т.п. су алу башняларына насослар белән идарә итү өчен автоматика сатып алу һәм урнаштыру
2. **Торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:**
   янгын гидранты җайланмасын сатып алу һәм урнаштыру:
   Көек-Ерыкса т.п.-2 шт.;

Яңа Комазан т.п.-1 шт.;
Зур Шыя т.п.-1 шт.;
Малмыжка -1 шт;
Гришкино- 1 шт.

«ӘЙЕ» «ЮК»

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге Башлыгы Ф.Р.Шәйхетдиновка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Көек-Ерыкса авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /Ф.Р.Шәйхетдинов /